КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 сентябрь г.Казань № 833

2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен;

2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 829 нчы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 829 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 сентябрь, 829 нчы карарлары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 сентябрь, 833 нче
карары белән расланды

2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәт күрсәтүләр исеме | Норматив чыгымнар, бер берәмлеккә 1 елга сум | 1 елга хезмәт күрсәтүләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Архив белешмә кәгазьләрен, архив күчермәләрен, архив өземтәләрен, гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле мәгълүмат хатларын бирү | 1 147,10 | 20 740 | үтәлгән соратып алулар саны, берәмлек |
| 2. | Архив документларыннан һәм аларның белешмә алу өчен эзләү чараларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 999,24 | 8 052 | уку залына керүләр саны, берәмлек |

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 сентябрь, 833 нче
карары белән расланды

2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 13 533 556 |
| 2. | Архив документларының сакланышын тәэмин итү һәм аларны исәпкә алу | 28 502 793 |
| 3. | Архив документларының тасвирламасын эшләү, аларның белешмә алу өчен эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә характерындагы мәгълүмат бирү басмаларын әзерләү | 6 679 710 |
| 4. | Архив документларындагы дәүләт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итә торган мәгълүматларны саклау һәм аларның сер булуын билгеләнгән тәртиптә бетерүне оештыру | 4 231 775 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәнең документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм методик ярдәм күрсәтү | 4 038 275 |
| 6. | Архив документларының белешмә алу өчен эзләү чараларыннан «ерактан торып» файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 4 503 025 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат чараларын, бастырып чыгару һәм күргәзмә проектларын тормышка ашыру | 7 883 770 |

______________________